

Үткән атнада Рузаевка районында «Кургоня 2021» дигән фестиваль онлайн һәм офлайн форматта vтте.
Татар Пешләсе клубы хезмәт-кәрләре, vзэшчән коллектив әгъза-лары белән бергә, бу фестивальдә актив катнаштылар. Чара этаплары-нын берсе Арх-Голицыно авылында vтте. Анда vзләренен чыгышлары, ягъни эчтәлекле номерлары белән тамашачыларны «Сандугачлар» ансамбле (житәкчесе Н.А.Чалдаева), Неля Рублевская, Шафика Неясова белән Равиль Кулаев шатландырдылар. Гармунчы Равиль vзенен гармунында виртуозларча уйнавы белән тамашачыны шаккаттырды, дип тә әйтергә момкин.
Фестивальдә Рузаевка районында яшәгән милләт кешеләре мәдәниятларынын һәм тарихла-рынын гvзәл vрнәкләреннән бай кvргәзмә оештырылган иде. Равиль Кулаевнын шәхси гармуннар кvргәзмәсе дә кызыклы булды.
«Сандугачлар» ансамбле белән Шафика Неясова Рузаевка шә-һәренен «Орион» дигән мәдәният йортында vткән фестивальнен ябылу тантанасында катнаштылар. Аларны, башка милли артистлар белән бергә, унышлы чыгышлары очен Грамоталар белән дә бvләкләнделәр.
Милли фестиваль горләп vтте. Халык кvп иттереп матур хисләр, киләчәккә коч туплап ойләренә таралыштылар. Шундый чаралардан ләззәт аласын, унай хисләр барлыкка килә.